**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__05_» _____06____ 2024 ел.** **№ ___108___**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2017 елның 20 декабрендәге 325 номерлы “Гражданлык яклау идарәсе” муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмә хакында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2024 елның 10 маендагы 315 номерлы “Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр төзегәндә исәпкә алына торган су объектларында халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасына үзгәреш кертү турында»гы номерлы карары нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2017 елның 20 декабрендәге 325 номерлы “Гражданлык яклау идарәсе” муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмә хакында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә (10.12.2019 №355, 02.08.2021 №173, 31.08.2021 №191, 03.11.2022 №346, 21.12.2022 №401 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. II бүлекнең 1 пунктының 1 нче таблицасы. Хезмәткәрләрнең хезмәт хакы (вазыйфа оклады, тариф ставкалары) күләмен яңа редакциядә бәян итәргә:

| № п/п | Хезмәткәрләрнең вазифалары | Вазыфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 25 014,00 |
| 2 | Оператив дежур | 19 242,00 |

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов